**СОВЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

**« 26 » гыйнвар 2016 ел** **№ 18**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы №17 Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: “2016 елда Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә карата, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Чернобыль АЭСында аварияне бетерүдә катнашучылар, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил итә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына | торак пунктларда юлларга вак таш җәю: | 668000,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | карата юл эшчәнлеге | Яңа Кенәр авылы | 357000 |
| | | Яңа Ашыт авылы | 20000 |
| | | Шурабаш авылы | 30000 |
| | | Шура авылы | 30000 |
| | | Байкал авылы | 60000 |
| | | Яңа Сәрдә авылы | 20000 |
| | | Сөрде авылы | 51200 |
| | | Югары Оры авылы | 31700 |
| | | Түбән Оры авылы | 40200 |
| | | Кызыл Яр авылы | 27900 |
| | Барлыгы: | 1 | 668000,00 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет ур., 10 й. Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде авылы, Совет ур., 48 й., Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин ур., 17 й.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.